РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423972, РТ, Муслюмовский район, с.Русский Шуган, ул.Ленинская,18
Pshug.Mus@tatar.ru_ тел. (8-85556) 3-70-37
ИНН 1629003946, КПП 162901001, ОГРН 1061687005170, ОКАТО 92242885000

Рус Шуган авыл 07 апрель 2021 г.

**Карар № 8**

**«Шуган авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Шуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 20 февраль 2017 ел, 5 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Шуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 20 февраль 2017 ел, 5 номерлы карары белән расланган «Шуган авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гарызнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шуган авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ю. Басорина